**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки муниципаль районы**
**Иске Камка авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Совет Старокамкинского сельского поселения**
**Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422897, ТР, Әлки районы,
Иске Камка авылы, Түбән урамы,1 йорт
тел./факс 8(84346) 73-524

Адрес: 422897, РТ, Алькеевский район, с. Старое Камкино, ул.Нижняя. д.1
тел./факс 8(84346) 73-524

**Р Е Ш Е Н И Е** Иске Камка **КАРАР**

2021 елның 30 ноябре 31 №

Җир салымы турында

1 статья Гомуми нигезләмәләр

1998 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясе Салым кодексы» N146-ФЗ Салым кодексы нигезендә һәм әлеге карар белән Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләнергә тиешле җир салымы (алга таба - салым) билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

2 статья Салым ставкасы

Салым ставкасы түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

- авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составына кертелгән һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган авыл хуҗалыгы зоналары составындагы җирләргә карата кадастр бәясенең 0,3%ы;

- Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларыннан тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) карата кадастр бәясенең 0,3% ы;

- оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,3 %ы;

- шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнарның бакчачылык һәм яшелчәчелек тармагын үз ихтыяҗлары өчен алып баруы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,13% ы;

- башка җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 1,5% ы.

3 статья. Җир салымының киметелгән ставкасы

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы бюджетларыннан һәм муниципаль берәмлек бюджетыннан, мәгариф учреждениеләреннән финанслана торган автоном учреждениеләрнең, бюджет учреждениеләренең, хакимият һәм идарә органнарының җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясенең 0,16 %ы.

4 статья. Салым ташламалары

Түбәндәге категория салым түләүчеләрне җир салымын түләүдән азат итәргә:

1) Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары;

2) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;

3) «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы (1992 елның 18 июнендәге 3061-I номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә), 1998 елның 26 ноябрендәге «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыкларны ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында» 175-ФЗ номерлы Федераль закон, 2002 елның 10 гыйнварындагы «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында» 2-ФЗ номерлы

Федераль законы нигезендә социаль ярдәм алуга хокукы булган физик затлар.

4) территориядә эшләүче янгыннан ирекле саклау әгъзаларының шәхси ярдәмче хуҗалык өлешендә.

5) сәнәгать билгеләнешендәге җир кишәрлекләрендә инвестицион бизнес-проектларны гамәлгә ашыручы инвесторлар.

6) зират, үләт базлары һәм гражданнар күмелгән җир кишәрлекләренә караган оешмалар һәм учреждениеләр.

7) мәйданнар, урамнар, эчке поселок юллары, скверлар, бульварлар, һәйкәлләр, су объектлары, су алу скважиналары, су җыю башнялары, ККК урнаштыру урыннары булган гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә караган муниципаль учреждениеләр.

## 5 статья. Хисап чоры

Календарь елы салым чоры һәм календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы салым түләүче оешмалар өчен хисап чоры дип танылa.

## 6 статья. Салым түләүчеләр тарафыннан салым салу базасын киметү хокукын раслый торган документлар тапшыру тәртибе

Салым түләүчеләр - салым ташламаларына, шул исәптән салым һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым базасын киметеп, салым ташламаларына хокуклы физик затлар, салым органына үзләре сайлаган салым ташламаларын бирү турында гариза, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

## 7 статья.

Түбәндәге норматив хокукый актларны үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 сентябрендәге «Җир салымы турында» 5 номерлы карары;

-Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2021 елның 7 июнендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2020 елның 23

сентябрендәге «Җир салымы турында» 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 6 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2021 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2021 елнын 7 июнендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 сентябрендәге «Җир салымы турында» 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»12 номерлы карары;

-Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2021 елның 29 ноябрендәге 16 номерлы карары.

8 статья. Әлеге карарның үз көченә керүе

Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән алып бер айдан да иртәрәк булмаган һәм тиешле салым буенча чираттагы салым чорының 1 нче числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге Совет Рәисе: Акберов Ф.Ә.